СОВЕТ КАНАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

27.09.2017 д. Канаш №30-135

Салым түләүчеләрнең аерым категорияләренә җир салымы түләү буенча салым ташламалары бирү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Янгыннан ирекле саклау турында» 2011 елның 6 маендагы 100-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау турында» 01.08.2011 № 48-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенә таянып,

Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Салым түләүчеләрнең түбәндәге категорияләренә җирнең кадастр бәясенең 0,2 %ы күләмендә җир салымының киметелгән ставкасын куллану рәвешендә җир салымы түләүгә салым ташламасын кертергә:

- янгыннан ирекле саклау буенча иҗтимагый берләшмәләргә;
- Янгыннан ирекле саклау хезмәткәрләренә һәм ирекле янгын сүндерүчеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктының 2 абзацында күрсәтелгән салым түләүчеләр өчен ташламалар эшкуарлык эшчәнлеге өчен файдаланылмый торган, ә берничә җир кишәрлеге (өлешләре) булган җир кишәрлекләренә карата бары тик бер җир кишәрлеге өчен генә бирелә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның 1 п.1 пунктында күрсәтелгән җир салымы буенча ташламалар хокукына ия затлар салым салу объекты дип таныла торган мөлкәт урнашкан урын буенча салым органына шушы ташламаны алу хокукын раслый торган документларны мөстәкыйль тапшыралар.

4. Әлеге карар 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз йогынтысын кагыла.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Вальков